КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 июнь г.Казань № 706

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 декабрь, 908 нче карары белән расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 декабрь, 908 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 март, 151 нче; 2016 ел, 18 июнь, 414 нче; 2016 ел, 9 ноябрь, 834 нче; 2018 ел, 30 июль, 618 нче; 2020 ел, 18 май, 402 нче; 2021 ел, 7 декабрь, 1181 нче, 2023 ел, 06 март, 215 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 пунктның таблицасында:

20 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чикләү чарасын сайлау турында суд карары күчермәсе (гаилә әгъзасы сак астына алынган очракта)»;

21 пунктның 2 графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзасына мәҗбүри медицина чарасы куллану турында суд карары күчермәсе (гаилә әгъзасы мәҗбүри дәвалануда булган очракта)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин